СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 7-4 от «15» декабря 2020 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 268-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә (12.11.2016 ел, № 3-12, 12.05.2017 ел, № 8-16, 26.07.2017 ел, № 4-18, 13.11.2017, №4-19, 29.06.2018 №10-27, 03.09.2018 № 8-28, 19.11.2018 № 11-29, 28.03.2019 №8-32, 23.07.2019 №17-34, 30.06.2020 ел, № 12-39 карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 12.3 пунктының 4 пунктчасында «хезмәт кенәгәсе» сүзләреннән соң «һәм (яки) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар» сүзләрен өстәргә;

1.2. 24.2 пунктындагы 4 пунктчага түбәндәге сүзләрне өстәргә:

«(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия

000119

Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү»;

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе — А.П.Иванов